# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## О развитии производства органической продукции в Республике Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 апреля 2021 года

### Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

1. Настоящий Закон регулирует отдельные вопросы в области производства органической продукции в Республике Татарстан (далее – производство органической продукции), а также определяет полномочия органов государственной власти Республики Татарстан в области производства органической продукции.

2. Настоящий Закон не распространяется на отношения, связанные с производством, хранением, транспортировкой и реализацией парфюмерно-косметической продукции, лекарственных средств, семян лесных растений, продукции охоты, рыбной продукции (за исключением продукции аквакультуры).

### Статья 2. **Правовое регулирование отношений в области производства органической продукции**

Правовое регулирование отношений в области производства органической продукции основывается на актах, составляющих право Евразийского экономического союза, и осуществляется в соответствии с Федеральным законом от 3 августа 2018 года № 280-ФЗ «Об органической продукции и о внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации» (далее – Федеральный закон «Об органической продукции и о внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации»), другими федеральными законами, иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, настоящим Законом и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан.

### Статья 3. **Понятия, используемые в настоящем Законе**

Для целей настоящего Закона используются следующие основные понятия:

1) органическая продукция – экологически чистые сельскохозяйственная продукция, сырье и продовольствие, производство которых соответствует требованиям, установленным Федеральным законом «Об органической продукции и о внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации»;

2) производство органической продукции – производство продукции растениеводства и животноводства, обособленное от производства продукции, не относящейся к органической, и осуществляемое с соблюдением иных требований, установленных Федеральным законом «Об органической продукции и о внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации»;

3) органическое сельское хозяйство – совокупность видов экономической деятельности, которые определены Федеральным законом от 29 декабря 2006 года № 264-ФЗ «О развитии сельского хозяйства» и при осуществлении которых применяются способы, методы и технологии, направленные на обеспечение благоприятного состояния окружающей среды, укрепление здоровья человека, сохранение и восстановление плодородия почв;

4) производители органической продукции – юридические и физические лица, которые осуществляют производство, хранение, маркировку, транспортировку и реализацию органической продукции и включены в единый государственный реестр производителей органической продукции.

### Статья 4. **Основные направления государственной политики Республики Татарстан в области производства органической продукции**

Основными направлениями государственной политики Республики Татарстан в области производства органической продукции являются:

1) развитие органического сельского хозяйства в Республике Татарстан;

2) повышение конкурентоспособности сельскохозяйственной продукции, произведенной в Республике Татарстан;

3) обеспечение населения качественными и безопасными пищевыми продуктами;

4) государственная поддержка производителей органической продукции в Республике Татарстан.

### Статья 5. **Полномочия Государственного Совета Республики Татарстан в области производства органической продукции**

К полномочиям Государственного Совета Республики Татарстан в области производства органической продукции относятся:

1) законодательное регулирование отдельных вопросов в области производства органической продукции;

2) утверждение в составе расходов бюджета Республики Татарстан объема средств, направляемых на государственную поддержку производителей органической продукции в Республике Татарстан;

3) контроль за соблюдением и исполнением законов Республики Татарстан в области производства органической продукции;

4) осуществление иных полномочий в соответствии с законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

Статья 6. **Полномочия Кабинета Министров Республики Татарстан в области производства органической продукции**

К полномочиям Кабинета Министров Республики Татарстан в области производства органической продукции относятся:

1) определение органа исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченного в области производства органической продукции в Республике Татарстан (далее – уполномоченный орган);

2) утверждение государственных программ Республики Татарстан в области производства органической продукции;

3) определение порядка предоставления мер государственной поддержки производителей органической продукции в Республике Татарстан;

4) определение объема средств бюджета Республики Татарстан, направляемых на государственную поддержку производителей органической продукции в Республике Татарстан;

5) осуществление иных полномочий в соответствии с законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

Статья 7. **Полномочия уполномоченного органа в области производства органической продукции**

К полномочиям уполномоченного органа в области производства органической продукции относятся:

1) разработка государственных программ Республики Татарстан в области производства органической продукции;

2) реализация на территории Республики Татарстан государственной поддержки сельскохозяйственных товаропроизводителей, осуществляющих производство органической продукции;

3) осуществление информационного и методического обеспечения в области производства органической продукции;

4) осуществление иных полномочий в соответствии с законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

Статья 8. **Государственная поддержка производителей органической продукции в Республике Татарстан**

Государственная поддержка производителей органической продукции в Республике Татарстан обеспечивается в порядке и формах, предусмотренных Федеральным законом от 29 декабря 2006 года № 264-ФЗ «О развитии сельского

хозяйства», и предоставляется в пределах средств бюджета Республики Татарстан, предусмотренных законом Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан на соответствующий финансовый год и на плановый период.

Статья 9. **Переход к органическому сельскому хозяйству и производству органической продукции**

1. При переходе к органическому сельскому хозяйству и производству органической продукции устанавливается переходный период, в течение которого обеспечивается внедрение правил ведения органического сельского хозяйства и производства органической продукции, установленных действующими в Российской Федерации национальными, межгосударственными и международными стандартами в области производства органической продукции.

2. Не допускается размещать маркировку органической продукции на упаковке, потребительской, транспортной таре сельскохозяйственной продукции, сырья и пищевых продуктов, произведенных в переходный период.

Статья 10. **Участие ассоциаций (союзов) производителей органической продукции в формировании и реализации государственной политики Республики Татарстан в области производства органической продукции**

К участию в формировании и реализации государственной политики Республики Татарстан в области производства органической продукции могут привлекаться на добровольной основе ассоциации (союзы) производителей органической продукции, осуществляющие свою деятельность в Республике Татарстан.

Статья 11. **Вступление в силу настоящего Закона**

Настоящий Закон вступает в силу через 30 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
05 мая 2021 года
№ 34-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүне үстерү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 апрелендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон Татарстан Республикасында органик продукция җитештерү (алга таба – органик продукция җитештерү) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга сала, шулай ук органик продукция җитештерү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының вәкаләтләрен билгели.

2. Әлеге Закон парфюмерия-косметика продукциясен, дару чараларын, урман үсемлекләре орлыкларын, аучылык продукциясен, балык продукциясен (аквакультура продукциясеннән тыш) җитештерү, саклау, транспортировкалау һәм реализацияләү белән бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый.

2 статья. **Органик продукция җитештерү өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Органик продукция җитештерү өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу Евразия икътисадый берлеге хокукын тәшкил иткән актларга нигезләнә һәм «Органик продукция турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 3 августындагы 280-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Органик продукция турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон), башка федераль законнар, Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төшенчәләр**

Әлеге Закон максатларында түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) органик продукция – «Органик продукция турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль

законда билгеләнгән таләпләргә туры китереп җитештерелә торган экологик чиста авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек;

2) органик продукция җитештерү – органик булмаган продукция җитештерүдән аерымланган һәм «Органик продукция турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законда билгеләнгән башка таләпләргә туры китереп башкарыла торган үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясен җитештерү;

3) органик авыл хуҗалыгы – «Авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән һәм әйләнә-тирә мохитнең имин торышына, кеше сәламәтлеген ныгытуга, туфрак уңдырышлылыгын саклап калуга һәм торгызуга юнәлдерелгән ысуллар, алымнар һәм технологияләр кулланып башкарыла торган икътисадый эшчәнлек төрләре җыелмасы;

4) органик продукция җитештерүчеләр – органик продукция җитештерүне, саклауны, маркировкалауны, транспортировкалауны һәм реализацияләүне гамәлгә ашыра торган һәм органик продукция җитештерүчеләрнең бердәм дәүләт реестрына кертелгән юридик һәм физик затлар.

4 статья. **Органик продукция җитештерү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләре**

Органик продукция җитештерү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) Татарстан Республикасында органик авыл хуҗалыгын үстерү;

2) Татарстан Республикасында җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясенең конкурентлыкка сәләтен арттыру;

3) халыкны сыйфатлы һәм куркынычсыз азык-төлек продуктлары белән тәэмин итү;

4) Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме.

5 статья. **Органик продукция җитештерү өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре**

Органик продукция җитештерү өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) органик продукция җитештерү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне законнар белән җайга салу;

2) Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары составында Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүчеләргә дәүләт ярдәменә җибәрелә торган акчалар күләмен раслау;

3) органик продукция җитештерү өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарының саклануын һәм үтәлүен тикшереп тору;

4) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне башкару.

6 статья. **Органик продукция җитештерү өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

Органик продукция җитештерү өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасында органик продукция җитештерү өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органын (алга таба – вәкаләтле орган) билгеләү;

2) органик продукция җитештерү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын раслау;

3) Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү тәртибен билгеләү;

4) Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүчеләргә дәүләт ярдәменә җибәрелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары күләмен билгеләү;

5) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне башкару.

7 статья. **Органик продукция җитештерү өлкәсендә вәкаләтле орган вәкаләтләре**

Органик продукция җитештерү өлкәсендә вәкаләтле орган вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) органик продукция җитештерү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү;

2) органик продукция җитештерүне башкаручы авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт ярдәмен гамәлгә ашыру;

3) органик продукция җитештерү өлкәсендә мәгълүмати һәм методик тәэмин итүне гамәлгә ашыру;

4) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне башкару.

8 статья. **Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме**

Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме «Авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә һәм рәвешләрдә тәэмин ителә һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары чикләрендә бирелә.

**9 статья. Органик авыл хуҗалыгына һәм органик продукция житештерүгә күчү**

1. Органик авыл хуҗалыгына һәм органик продукция житештерүгә күчкәндә күчеш чоры билгеләнә, әлеге чорда Россия Федерациясендә гамәлдә булган органик продукция җитештерү өлкәсендә илкүләм, дәүләтара һәм халыкара стандартлар белән билгеләнгән органик авыл хуҗалыгын алып бару һәм органик продукция җитештерү кагыйдәләрен кертү тәэмин ителә.

2. Күчеш чорында җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек продуктлары төргәгенә, куллану, транспорт әрҗәләренә органик продукция маркировкасын урнаштыру рөхсәт ителми.

**10 статья. Органик продукция җитештерүчеләр ассоциацияләренең (берлекләренең) органик продукция җитештерү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтен булдыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашуы**

Органик продукция җитештерү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтен булдыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашуга Татарстан Республикасында үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыра торган органик продукция җитештерүчеләр ассоциацияләре (берлекләре) ирекле рәвештә җәлеп ителергә мөмкин.

**11 статья. Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 30 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН *
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 05 май
№ 34-ТРЗ